СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **№3**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында Казанка авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорты адресы буенча урнашкан Сурнар авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 10 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында Казанка авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорты адресы буенча урнашкан Сурнар авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 10 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:

1 нче этап: Үзәк, Чишмә урамнарында яшәүчеләр.

2 нче этап: Җиңү урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 335 сум тәшкил иткән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 670 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлның буй профилен төзәтү; зиратка юл салу; кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)

-урамнарны яктырту җайланмасы (Үзәк һәм Җиңү урамнары арасындагы юлны яктырту; яктырткычлар сатып алу)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге

башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күплэп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанка авылы, Җиңү урамы, 1нче йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанка авылы, Үзәк урам, 18 нче йорт.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков